**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

2021елның 25 феврале 14-РС номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, 2021 елның 02 февралендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен, 2021 елның 03 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 августындагы 46 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирп авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 95 номерлы карарлары әлеге карар үз көченә кергән вакыттан үз көчләрен югалткан дип танырга.
5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**